КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 10 гыйнвар г.Казань № 7

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 25 май, 298 нче; 2018 ел, 21 май, 384 нче; 2019 ел, 25 гыйнвар, 38 нче; 2020 ел, 12 март, 187 нче; 2020 ел, 21 сентябрь, 850 нче; 2021 ел, 15 февраль, 81 нче; 2021 ел, 21 июль, 636 нчы; 2021 ел, 23 октябрь, 998 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 945 нче; 2023 ел, 23 май, 628 нче; 2023 ел, 17 июль, 840 нчы; 2023 ел, 4 сентябрь, 1068 нче; 2024 ел, 4 июль, 507 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турындагы нигезләмәнең 14 пунктында «Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре» сүзләрен «дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар вәкилләре, шулай ук башка затлар» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе комитеты составында Римма Атлас кызы Ратникованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты каршындагы Эксперт советы рәисе урынбасары (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин